


Укытучы нинди булырга тиеш, ә яна заман укытучысы нинди булырга тиеш сон? Менә шул сорауга жавап эзлэгәндә Саранск шәһәре башлангыч сыйныф укытучысы Карина Рафик кызы Барсукова белән интернет аша таныштым.
Хәзерге заман мәктәбенен ин зур бурычы - уйларга, фикер йортергә сәләтле, заман сулышын тоеп, алга атлаучы, уйлап табучан, югары әхлаклы, vз халкынын тарихын, мәдәниятын белvче ижади шәхес тәрбияләv дип әйтер идем. Сонгы елларда безнен тормышыбыз бик нык алга китте. Тормышыбызнын һәр олкәсенә фән-техника казанышлары буларак компьютерлар, электрон исәпләv машиналары килеп керде. Заман кешеләрнен акыллы, тирән белемле булуын таләп итә. Шуна кvрә дә хәзерге шартларда мәктәпкә vзенен предметын югары дәрәҗәдә белгән, балаларнын яшь vзенчәлекләрен, психологиясен яхшы анлаган, vз һонәренен остасы булган, балаларны мостәкыйль фикер йортергә ойрәтә, аларны һәрьяклап ача белә торган укытучылар кирәк.
Шундый укытучы булыр очен vз-vзенә таләпчән булырга, эзләнергә, яналыкларны ойрәнеп, аларны эш барышында куллана белергә, vзенне башкалар белән чагыштырып читтән торып бәя дә бирә белергә кирәк. Ә бит чын укытучы vз эшенен нәтижәсе яхшы булсын очен ботен кvнелен биреп эшли, балаларнын язмышы очен борчыла. Кирәк икән, ул артист, рәссам, шагыйрь дә була. Һәр баланын кечкенә генә булса да сәләтен кvреп, аны vстереп, балада vз-vзенә карата ышаныч тудырып, кирәк икән бәхәсләшеп, котелгән

нәтижәгә дусларча монәсәбәт аша ирешергә момкин. Һәр балага шәхес буларак формалашырга, тормышта авырлыклар алдында каушап калмаска, аны vз гамәлләренә һәм хезмәтенә дорес бәя бирә алырдай итеп тәрбияләргә бурычлы бvгенге кон укытучысы. Шул таләпләргә туры килә дә инде Карина Рафик кызы Барсукова. Ул - vзенен ботен тырышлыгын, ботен кочен, ботен барлыгын балаларга бирvче кеше: доньядагы барлык унай сыйфатларны vзенә туплаган, кин кvнелле, сабыр кеше ул. Балаларны кvз карашыннан анлаучы, топле кинәшләрен бирvче дә ул. Әлеге педагог заманнан бер адым да калышмыйча атлый. Чонки ул балалар аласы бик кvп белемнәрнен нигезен салучы кеше. «Ел укытучысы-2022» конкурсынын суперфиналисты Карина Рафик кызы белән аралашканда һонәрегезне ни очен яратасыз дип сорадым, ә ул:
- Кон саен балалар белән бергә ниндидер яналык белvем очен дә, - ди Карина Рафик кызы Барсукова. - Минем очен һәр дәрес - укучыларымны гажәпләндерv момкинлеге ул.

Якынрак танышыйк анын белән. Карина Рафиковна Саранск шәһәрендә туа һәм озакламый, әтисе хәрби кеше булганга, Ерак Кончыгыш хәр-би шәһәрчегенә кvчеп яши башлыйлар. Ә бишенче класска кvчкәч, Саранскига кайтып тора башлыйлар. Урта мәктәпне тәмамлап, хыялын тормышка ашырып, М.Е.Евсевьев исемендәге Мордовия педагогия институтында башлангыч сыйныфлар укытучысы, музыка укытучысы белгечлеген ала. Әйтеп китәргә кирәк, Карина музыка мәктәбендә дә, әтисенен vгет-нәсихәтләре ярдәмендә, унышлы укып чыга. Педагогика вузы дипломын алгач, ул шулай ук «Югары мәктәп педагогикасы» юнәлеше буенча магистратураны тәмамлый. Башлангыч сыйныф укытучысы буларак хезмәт юлын Саранск шәһәренен 20 нче гимназиясендә башлый ул. Ярты елдан сон Карина Рәфыйк кызы Барсукова яшь укытучыларнын «Педагогик дебют» гимназия конкурсында катнашып жинv яулый. Бер елдан сон яшь укытучыларнын «Признание» шәһәр конкурсында призер була.



[illegible]